**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НАРМОНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
422630,РТ,Лаишевский район, село
Нармонка, ул.Молодежная , д.12 А
8-(84378) -4-62-24
факс: 8-(84378) -4-62-24

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
НАРМОНКА АВЫЛ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422630, РТ,Лаеш районы, Нармонкаавылы,
Яшьләр урамы, 12 Анчейорт
тел: 8-(84378) -4-62-24
факс: 8-(84378) -4-62-24

---

**2020елның «4 » августы** **10 номер**

**КАРАР**

**Нармонка авыл җирлеге Советына депутатлыкка
кандидатларның сайлаучылар белән очрашуларын үткәрү
өчен махсус билгеләнгән урыннар бүлеп бирү турында.**

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Нармонка авыл җирлеге Советына депутатлыкка кандидатлар өчен 1740,1741,1742,1744 сайлау участоклары территориясендә сайлаучылар белән очрашуларын үткәрү өчен махсус билгеләнгән урыннар бүлеп бирү турында Татарстан Республикасы Лаеш районы территориаль сайлау комиссиясе тәкъдимен карап тикшергәннән соң, «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 54 статьясындагы 7 пунктына, Татарстан Республикасы Сайлау Кодексының 64 статьясындагы 8 пунктына таянып, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Нармонка авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Нармонка авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Нармонка авыл җирлеге Советы депутатлыгына кандидатларның сайлаучылары белән очрашу өчен махсус бирелгән урын итеп Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Нармонка авылы, Яшьләр урамы, 12 А.йорт, Әстерхан МТФ бинасы; Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Әстерхан авылы, Большая урамы, «Нармонка» АФ» ҖЧҖ конторасы бинасы; Татарстан Республикасы, Лаеш районы, Нармонка авылы, Үзәк урамы, 24 йорт; Тат.Кабан авыл клубы бинасы: Татарстан Республикасы, Лаеш районы, Татар Кабан авылы, Солнечная урамы, 16А. адресларын билгеләргә.
2. Карарны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының территория сайлау комиссиясенә җибәрергә.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Нармонка авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе** **Л.Д.Стерякова**